| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 сентябрь № 684

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 ноябрь, 845 нче карары белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 ноябрь, 845 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1071 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы

исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча граждannар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 13 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Урта һөнәр белеме һөнәрләре һәм белгечлекләре буенча кабул итүнең контроль саннарын билгеләү буенча конкурс нигезендә сайлап алу үткәрү белем бирү оешмалары эшчәнлегенең түбәндәге күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла:

а) Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда алынган һөнәр (белгечлек) буенча эшкә урнашкан урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар өлеше;

б) Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда укуын тәмамлап чыгучыларның гомуми санында белем бирү оешмасында укуын тәмамлаганнан соң бер ел эчендә «Россия Федерациясендә халыкның эш белән тәэмин ителеше турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә эшсезләр дип танылмаган белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар санының чагыштырма авырлыгы;

в) план чоры алдыннан килә торган соңгы ике ел эчендә урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасына укырга кабул итү планын үтәү;

г) Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килә торган ике ел эчендә халыкара, бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында, һөнәри конкурсларда һәм башка шундый чараларда (интернет-конкурслардан тыш) җиңүчеләр һәм призлы урыннар алучылар булган һөнәр белеме алучы студентлар өлеше;

д) укытучыларның һәм һөнәр (белгечлек) буенча производство белеме бирү мастерларының квалификация дәрәҗәсе;

е) һөнәрләр циклы укытучыларының һәм производство белеме бирү мастерларының квалификациясен күтәрү;

ж) һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучыларның һәм производство белеме бирү мастерларының гомуми санында тиешле һөнәри өлкә оешмаларында эшләү тәҗрибәсе булган һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары өлеше;

з) һөнәр (белгечлек) буенча басма һәм (яки) электрон дәреслекләр белән тәэмин ителеш;

и) уку-укыту процессының компьютерлар белән тәэмин ителеше;

к) белем бирү оешмасы һәм эш бирүче арасында студентларны әзерләү һәм эшкә урнаштыру өлешендә хезмәттәшлек турында шартнамә(-ләр) булу;

л) белем бирү оешмасының тулай торагы булу;

м) производство белеме бирү мастерларының һөнәр буенча квалификация дәрәҗәсе.»;

Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтаның 4 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Конкурста катнашучылар гаризаларын бәяләүне һәм чагыштыруны конкурс комиссиясе түбәндәге таблица нигезендә башкара.

| Т/с | Критерий исеме | Критерийны билгеләү | Критерийны балларда исәпләү |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда алынган һөнәр (белгечлек) буенча эшкә урнашкан урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар өлеше | Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар санына карата Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда алынган һөнәр (белгечлек) буенча эшкә урнашкан урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар саны мөнәсәбәте | $К1 = Ч_{вт}/Ч_{во} \times 100$,<br>монда:<br>$Ч_{вт}$ – Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда алынган һөнәр (белгечлек) буенча эшкә урнашкан белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар саны;<br>$Ч_{во}$ – Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар саны |
| 2. | Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда укуын тәмамлап чыгучыларның гомуми санында белем бирү оешмасында укуын тәмамлаганнан соң бер ел эчендә «Россия Федерациясендә халыкның эш белән тәэмин ителеше турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә эшсезләр дип танылмаган белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар санының чагыштырма авырлыгы | Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда укуын тәмамлап чыгучыларның гомуми санына карата укуын тәмамлаганнан соң бер ел эчендә эшсез дип танылган белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар саны мөнәсәбәте | $К2 = (1 - Ч_{вб}/Ч_{во}) \times 100$,<br>монда:<br>$Ч_{вб}$ – укуын тәмамлаганнан соң бер ел эчендә халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында исәптә торучы белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар саны;<br>$Ч_{во}$ – Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче елда белем бирү оешмасын тәмамлап чыгучылар саны |
| 3. | План чоры алдыннан килә торган соңгы ике ел эчендә урта һөнәр белеме бирү | Соңгы ике елга суммада контроль кабул итү саннарының билгеләнгән күләменә карата план | $К3 = Ч_{фгз} / Ч_{пгз} \times 100$,<br>монда:<br>$Ч_{фгз}$ – план чоры алдыннан килә торган соңгы ике ел |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | программалары буенча белем бирү оешмасына укырга кабул итү планын үтәү | чоры алдыннан килә торган соңгы ике ел эчендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасына укырга кабул итүнең факттагы саны мөнәсәбәте | эчендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү оешмасына укырга кабул итүнең факттагы саны;<br>$Ч_{пгз}$ – соңгы ике елга суммада контроль кабул итү саннарының билгеләнгән күләме |
| 4. | Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килә торган ике ел эчендә халыкара, бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында, һөнәри конкурсларда һәм башка шундый чараларда (интернет-конкурслардан тыш) җиңүчеләр һәм призлы урыннар алучылар булган һөнәр белеме алучы студентлар өлеше | Конкурс үткәрелә торган ел башына һөнәр белеме алучы студентлар санына карата Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килә торган ике ел эчендә халыкара, бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында, һөнәри конкурсларда һәм башка шундый чараларда (интернет-конкурслардан тыш) җиңүчеләр һәм призлы урыннар алучылар булган һөнәр белеме алучы студентлар саны мөнәсәбәте | К4 = Сп / С х 100,<br>монда:<br>Сп – Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килә торган ике ел эчендә халыкара, бөтенроссия һәм республика олимпиадаларында, һөнәри конкурсларда һәм башка шундый чараларда (интернет-конкурслардан тыш) җиңүчеләр һәм призлы урыннар алучылар булган һөнәр белеме алучы студентлар саны;<br>С – Конкурс үткәрелә торган ел башына һөнәр белеме алучы студентлар саны |
| 5. | Укытучыларның һәм һөнәр (белгечлек) буенча производство белеме бирү мастерларының квалификация дәрәҗәсе | Төп һөнәр белеме бирү программалары (алга таба – белем бирү программалары) кысаларында һөнәри модульләрне тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучыларның һәм производство белеме бирү мастерларының гомуми санына карата югары яки беренче квалификация категориясе булган, | К5 = $Ч_{пв}$ / $Ч_{п}$ х 100,<br>монда:<br>$Ч_{пв}$ – югары яки беренче квалификация категориясе булган, белем бирү программалары кысаларында һөнәри модульләрне тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары саны;<br>$Ч_{п}$ – белем бирү программалары кысаларында |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | белем бирү программалары кысаларында һөнәри модульләрне тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары саны мөнәсәбәте | һөнәри модульләрне тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучыларның һәм производство белеме бирү мастерларының гомуми саны |
| 6. | Һөнәрләр циклы укытучыларының һәм производство белеме бирү мастерларының квалификациясен күтәрү | Белем бирү программалары кысаларында һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары санына карата Конкурс үткәрелә торган ел алдыннан килүче соңгы өч ел эчендә квалификациясен күтәргән һөнәрләр циклы укытучылары һәм производство белеме бирү мастерлары саны мөнәсәбәте | К6 = $Ч_{пм}$ / $Ч_{опм}$ х 100,<br>монда:<br>$Ч_{пм}$ – соңгы өч ел эчендә квалификациясен күтәргән белем бирү программаларын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары саны;<br>$Ч_{опм}$ – белем бирү программалары кысаларында һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучыларының һәм производство белеме бирү мастерларының гомуми саны |
| 7. | Һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучыларның һәм производство белеме бирү мастерларының гомуми санында тиешле һөнәри өлкә оешмаларында эшләү тәҗрибәсе булган һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары өлеше | Белем бирү программалары кысаларында һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары санына карата тиешле һөнәри өлкә оешмаларында эшләү тәҗрибәсе булган, һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары саны мөнәсәбәте | К7 = $Ч_{од}$ / $Ч_{пц}$ х 100,<br>монда:<br>$Ч_{од}$ – тиешле һөнәри өлкә оешмаларында эшләү тәҗрибәсе булган, һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары саны;<br>$Ч_{пц}$ – белем бирү программалары кысаларында һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче укытучылар һәм производство белеме бирү мастерлары саны |
| 8. | Һөнәр (белгечлек) | Һөнәр (белгечлек) буен- | К8 = $Э_у$ /$М_о$ х 100, |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | буенча басма һәм (яки) электрон дәреслекләр белән тәэмин ителеш | ча федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә укуукыту планы белән күздә тотылган уку-укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләр санына карата соңгы биш елда төп һәм өстәмә уку әдәбиятының басма һәм (яки) электрон дәреслекләре булган уку-укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләр мөнәсәбәте | монда:<br>$Э_у$ – соңгы биш елда төп һәм өстәмә уку әдәбиятының басма һәм (яки) электрон дәреслекләре булган уку-укыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләр саны;<br>$М_о$ – һөнәр (белгечлек) буенча федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә уку-укыту планы белән күздә тотылган укуукыту дисциплиналары һәм һөнәри модульләр саны |
| 9. | Уку-укыту процессының компьютерлар белән тәэмин ителеше | Көндезге формада укучы бер студентка туры килә торган компьютерлар саны | К9 = $К_к$ / $Ч_о$ х 100,<br>монда:<br>$К_к$ – компьютерлар саны;<br>$Ч_о$ – көндезге формада белем алучы студентлар саны |
| 10. | Белем бирү оешмасы һәм эш бирүче арасында студентларны әзерләү һәм эшкә урнаштыру өлешендә хезмәттәшлек турында шартнамә(-ләр) булу | Әйе<br><br>Юк | К10 = 5 балл<br><br>К10 = 0 балл |
| 11. | Белем бирү оешмасының тулай торагы булу | Әйе - 10 балл<br><br>Юк - 0 балл | К11 = 10 балл<br><br>К11 = 0 балл |
| 12. | Производство белеме бирү мастерларының һөнәр буенча квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программалары кысаларында һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче производство белеме бирү мастерлары санына карата урта һөнәр белеме бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә әлеге һөнәр буенча укуны тәмамлау- | К12 = $Ч_{мр}$ / $Ч_{мх}$ 100,<br>монда:<br>$Ч_{мр}$ – урта һөнәр белеме бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандарты нигезендә әлеге һөнәр буенча укуны тәмамлаучылар өчен күздә тотылганга караганда эшче һөнәре буенча бер яки ике разрядка югарырак булган производство белеме бирү мастерлары саны; |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | чылар өчен күздә тотылганга караганда эшче һөнәре буенча бер яки ике разрядка югарырак булган производство белеме бирү мастерлары саны мөнәсәбәте | $Ч_м$ – белем бирү программалары кысаларында һөнәрләр циклын тормышка ашыруны тәэмин итүче производство белеме бирү мастерлары саны |

Искәрмә: Балларны йомгаклап исәпләгәндә К1-К9, К12 күрсәткечләре 10га бүленә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин